Боерык

04 октябрь 2013 293 №лы

**«Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр, шул исәптән метрополитен, шәһәрьяны һәм шәһәрара (тимерьюл транспортыннан тыш) элемтәдәге бөтен иҗтимагый транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләрен карау тәртибенең раслануы турында» 11.06.2013 159 №лы боерыгына үзгәртүләр кертү турында**

Агымдагы законнарга туры китерү максатыннын чыгып

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр, шул исәптән метрополитен, шәһәрьяны һәм шәһәрара (тимерьюл транспортыннан тыш) элемтәдәге бөтен иҗтимагый транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләрен карау тәртибенең раслануы турында» 11.06.2013 159 №лы боерыгына (моннан соң – Боерык) түбәндәге үзгәртүләр кертергә:

Боерыкның Кушымтасына:

19 нчы пункт «тарифлар билгеләү эшләренең тикшерүен туктатырга» сүзләре алдыннан «әлеге Тәртипнең 45 нче пунктында күрсәтелгән тиешле карарлар кабул ителүе белән» сүзләрен кушырга;

45 нче пунктның икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләренең каралуы түбәндәге карарларыннан берсенең кабул ителүе белән туктатыла:

1) Пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләренең Дәүләт комитетының карары;
2) Дәүләт комитетының эш каралуның туктатылуы турында боерыгы;
3) Дәүләт комитетының тарифлар билгеләүне кире кагу турында боерыгы.»;

45 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле өченче абзац кушарга:

«Идарәнең утырышларында кабул ителгән карарлары турындагы мәгълүмат карарның кабул ителгән көненнән башлап бер көн эчендә Дәүләт

комитетының рәсми сайтында нәшер ителә (http://kt.tatarstan.ru).»;

46 нчы пункт Боерыкның Кушымтасы 47 нчы пункт Боерыкның Кушымтасы дип санарга;

Боерыкның Кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 46 нчы пункт кушарга:

«46. Идарә утырышыннан соң 10 календарь көне эчендә:

Дәүләт комитетының эш каралуның туктатылуы турында яки тарифлар билгеләүне кире кагу турында боерыгының һәм Идарә утырышының беркетмәсенең күчермәләре гариза бирүчегә җибәрелә;

Пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләренең Дәүләт комитетының карарының һәм Идарә утырышының беркетмәсенең күчермәләре гариза бирүчегә һәм Тарифлар буенча федераль хезмәткә җибәрелә.

Татарстан Республикасының Юстиция министырлыгында дәүләти теркәлү көненнән соң ун көн эчендә Пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү эшләренең Дәүләт комитетының карары «Татарстан Республикасының Юстиция министырлыгының рәсми хокукый мәгълүмат сайтында» (pravo.tatarstan.ru) һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтының (http://kt.tatarstan.ru) «Норматив документлар» бүлегендә нәшер ителә».

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә нәшер ителгән көнне гамәлгә керә.

3. Элеге боерыкның үтәлү контроле үз өстемдә кала.

Председатель М.Р. Зарипов